

# Сказка о царе Салтане, о сыне его славном и могучем богатыре князе Гвидоне Салтановиче и о прекрасной царевне Лебеди

•

# Салтан патша белән аның данлы, куәтле улы баһадир князь Гвидон Салтанович һәм гүзәл патша кызы Аккош турында әкият





Три девицы под окном
Пряли поздно вечерком.
«Кабы я была царица, –
Говорит одна девица, –
То на весь крещёный мир
Приготовила б я пир».
«Кабы я была царица, –
Говорит её сестрица, –
То на весь бы мир одна
Наткала я полотна».
«Кабы я была царица, –
Третья молвила сестрица, –
Я б для батюшки-царя
Родила богатыря».

Только вымолвить успела,
Дверь тихонько заскрипела,
И в светлицу входит царь,
Стороны той государь.
Во всё время разговора
Он стоял позадь забора;
Речь последней по сему
Полюбилася ему.
«Здравствуй, красная девица, –
Говорит он, – будь царица

Өч кыз тәрәзә төбендә
Кичен җеп эрләгәндә,
«Булсам мин бер патшабикә, –
Дип, берсе сүз башлап китә, –
Бөтен дөньяга үзем
Мин сый әзерләр идем».
«Мин булсам ул патшабикә, –
Дип, сеңлесе сөйләп китә, –
Бөтен дөньяга үзем
Ак киндер тукыр идем».
«Ә мин булсам патшабикә, –
Дип, өченче матур әйтә, –
Табар идем патшага
Мин бер баһадир бала».

Тик сүзен ул тәмам итә,
Ишек әкрен ачылып китә,
Һәм килеп керә патша –
Зур хөкемдар шул якта.
Кызлар сөйләшкән чагында,
Патша торган өй артында.
Соңгы кыз сүзе аңа
Һәр яктан ошап кала.
«Исәнме, – ди, – кыз матуры,
Бул, әйдә, патша хатыны



И роди богатыря
Мне к исходу сентября.
Вы ж, голубушки-сестрицы,
Выбирайтесь из светлицы.
Поезжайте вслед за мной,
Вслед за мной и за сестрой:
Будь одна из вас ткачиха,
А другая повариха».

В сени вышел царь-отец.
Все пустились во дворец.
Царь недолго собирался:
В тот же вечер обвенчался.
Царь Салтан за пир честной
Сел с царицей молодой;
А потом честны́е гости
На кровать слоновой кости
Положили молодых
И оставили одних.
В кухне злится повариха,
Плачет у станка ткачиха,
И завидуют оне
Государевой жене.
А царица молодая,
Дела вдаль не отлагая,
С первой ночи понесла.

В те поры война была.
Царь Салтан, с женой простяся,
На добра коня садяся,
Ей наказывал себя
Поберечь, его любя.

Һәм сентябрь ахырына
Тап бер баһадир бала.
Ә сез, кызлар-күгәрченнәр,
Кузгалыгыз бүлмәгездән,
Минем белән сеңлегез
Артыннан юнәлегез.
Булсын берегез тукучы,
Ә икенчегез – аш-сучы».

Патша чыга урамга,
Бар да китә сарайга.
Салтан күпкә сузмый эшне,
Никахлана шул ук кичне.
Утыра туйда түрдә
Яшь матур бикә белән.
Туй беткәч, илтеп чарлакка,
Фил сөякле караватка
Ике яшьне салалар
Һәм ялгыз калдыралар.
Кухняда тузгый аш-сучы,
Станда елый тукучы,
Көнләшеп шашыналар
Патшабикәдән алар.
Ә патшаның яшь хатыны,
Биргән сүзен үтәп тулы,
Шул төн авырга кала.

Ул вакыт сугыш барган.
Бикәгә кул биреп, патша,
Аргамакка менгән чакта:
«Саклый күр үзеңне, – ди, –
Әгәр сөйсәң мине», – ди.



Между тем, как он далёко
Бьётся долго и жестоко,
Наступает срок родин;
Сына бог им дал в аршин,
И царица над ребёнком,
Как орлица над орлёнком;
Шлёт с письмом она гонца,
Чтоб обрадовать отца.
А ткачиха с поварихой,
С сватьей бабой Бабарихой
Извести её хотят,
Перенять гонца велят;
Сами шлют гонца другого
Вот с чем о́т слова до слова:
«Родила царица в ночь
Не то сына, не то дочь;
Не мышонка, не лягушку,
А неведому зверюшку».

Как услышал царь-отец,
Что донёс ему гонец,
В гневе начал он чудесить
И гонца хотел повесить;
Но, смягчившись на сей раз,
Дал гонцу такой приказ:
«Ждать царёва возвращенья
Для законного решенья».

Едет с грамотой гонец
И приехал наконец.
А ткачиха с поварихой,
С сватьей бабай Бабарихой

Шулай итеп, ул еракта,
Каты сугышларда чакта,
Көне җиткәч, таба ана
Аршын буйлы ир бала.
Һәм ул саклый үз баласын,
Әйтерсең лә ана лачын;
Җибәрә ул илче дә
Патшага сөенчегә.
Ә тукучы һәм пешекче,
Кодагый карчык-кендекче
Хатынга үч тоталар,
Илчене туктаталар.
Җибәрә илче үзләре,
Хатка язып бу сүзләрне:
«Тапты хатының монда
Ни кыз, ни малай шунда,
Ни бака, ни тәкәрлек ул,
Әллә нинди бер җәнлек ул».

Белгәч патша шул мәлне
Илчедән бу хәбәрне,
Ачулана, ярсый, туза,
Илчене асмакчы була.
Ләкин, йомшап бу юлга,
Боерык бирә ул шунда:
«Закончა эш итәр өчен,
Патша кайтуы көтелсен».

Илче хат белән китә.
Ниһаять, кайтып җитә.
Ә тукучы һәм пешекче,
Кодагый карчык-кендекче